| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАП-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2025 ел. Потап-Томбарлы авылы № 136

«Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының Потап-Томбарлы
авыл җирлеге Советы карарына үз вәкаләтләрен
даими нигездә гамәлгә ашыручы
җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи
затларының, җирле үзидарә органнарының
муниципаль хезмәткәрләренең
Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының Потап-Томбарлы
авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр
кертү турында» 2018 елның 13 апрелендәге
55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә Баулы муниципаль районының Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 13.04.2018 елның 55 номерлы карарына «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге җирле үзидарә

органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» кертергә (Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 07.05.2018 № 59, 22.10.2018 № 76, 20.11.2018 № 81, 12.09.2020 № 138, 17.12.2021 № 36, 28.09.2022 № 52, 20.12.2022 № 65, 28.06.2024 № 112, 15.11.2024 № 123 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр:

1 пунктның 3 абзацында «13 990» санын «15 389» санына алмаштырырга;

2 пунктның 2.1 пунктчасының 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районның авыл җирлеге башлыгына хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә елына 15,48 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан артмаска тиеш.»;

6 нчы кушымтада «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

13 нче кушымтаның 1 пунктында:

6 пунктчада) «41 процент» сүзләрен «58 процент»сүзләренә алмаштырырга.

күрсәтелгән карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үз көчен 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык, Совет Рәисе
Потап-Томбарлы авыл җирлеге С. А. Козлова

Приложение № 2
к решению Совета
Потапово-Тумбарлинского
сельского поселения
Бавлинского муниципального района
от 13.04.2018 г. № 55

(в редакции решения Совета
Потапово-Тумбарлинского
сельского поселения
Бавлинского муниципального района
от 30.04.2025 г. № 136

Размеры денежного вознаграждения Главы Потапово-Тумбарлинского сельского поселения Бавлинского муниципального района

| Наименования должностей | Размеры денежного вознаграждения (в рублях) |
|---|---|
| | 12 группа |
| Глава сельского поселения | 21 091 |